Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районының
Арча шәһәр муниципаль берәмлеге
Арча шәһәр
башкарма комитеты

422000, Арча ш. Совет мәйданы, 27
тел. 3-16-25, 3-12-35

Муниципальное образование
город Арск
Арского муниципального района
Республики Татарстан
исполнительный комитет
города Арск
422000, г. Арск, площадь Советская, 27
тел. 3-16-25, 3-12-35

---

# КАРАР

**«05» май, 2026 ел** **№ 53**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Арча шәһәре Башкарма комитетының “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге территориясендә сүтелә торган (киселә торган) яшел үсентеләр бәясен исәпләү һәм компенсацион яшелләндерү үткәрү методикасын раслау турында” 2025 елның 27 февралендәге 54 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

“Әйләнә-тирә мохитне саклау турында” 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә Арча шәһәре Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Арча шәһәре Башкарма комитетының “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге территориясендә сүтелә торган (киселә торган) яшел үсентеләр бәясен исәпләү һәм компенсацион яшелләндерү үткәрү методикасын раслау турында” 2025 елның 27 февралендәге 54 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

1) 1.3 пунктның 3 абзацын төшереп калдырырга;

2) 1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Яшел утыртмаларны хокуксыз зарарлаганда яисә юкка чыгарганда зыянны исәпләү Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нигезендә гамәлгә ашырыла».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында (https://arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Арча шәһәре Башкарма
комитеты җитәкчесе Р. Р. Баһаветдинов